ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 Казан ш. № 5-20/тэ

2019 елга "Кулонэнергомаш" акционер җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2019 елга тарифлар билгеләү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Кулонэнергомаш" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 21 ноябрендәге 5-20/тэ
номерлы карарына кушымта

"Кулонэнергомаш" акционер җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга
бирелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә)
2019 елга, календарь бүленештә күрсәтеп, тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме, тариф төре | Ел | Су | Иң көчле басымлы пар | | | | Коры һәм көчсезләндерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 алып 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 алып 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 алып 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ күбрәк | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Кулонэнергомаш» акционер җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар бүлеп каралмаган очракта, кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 1294,00 | - | - | - | - | - |
| | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 1323,19 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 1552,80 | - | - | - | - | - |
| | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 1587,83 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге